| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

02.08.2024 Баулы шәһәре № 135

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының 2022 елның 26 декабрендәге 85/1 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2009 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, гавами тыңлаулар беркетмәсе, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында комиссия бәяләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге Уставы белән, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының 2022 елның 26 декабрендәге 85/1 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең генераль планына, кушымта нигезендә, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендә http://bavly.tatarstan.ru һәм Баулы муниципаль районы сайтында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль район Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләтергә.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы Рәисе И.И. Гозәеров